СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 4-33 от «16» сентября 2024 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс турында

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылуга бәйле рәвештә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 19 статьясына, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы уставының 46 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс игълан итәргә.

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучылардан конкурска документлар кабул итү Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү турындагы хәбәр «Нократ» («Вятка») газетасында рәсми басылып чыккан көннән алып 20 көн эчендә башкарырга. Документлар түбәндәге адрес буенча бирелә: Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Мамадыш шәһәре, М.Җәлил ур., 23/33 йорт, 313 нче кабинет, 8.00 дән 12.00 сәгатькә кадәр һәм 13.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, ял һәм бәйрәм көннәреннән тыш, телефон 3-11-29.

3. Конкурсны 2024 елның 16 октябрендә 10.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Мамадыш шәһәре, М.Җәлил ур., 23/33 йорт адресы буенча, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 31.05.2024 елның 31 маенда кабул ителгән № 4-31 карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турында Нигезләмәгә таянып, үткәрергә.

4. Нигезләмә нигезендә конкурс комиссиясе 6 кешедән тора дип билгеләргә.

000087

5. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына кандидатларны карау буенча конкурс комиссиясе әгъзаларының яртысын түбәндәге составта билгеләргә:

| | |
|---|---|
| Сәмигуллин Ришат Роберт улы | – комиссия рәисе, Мамадыш муниципаль районы башлыгы урынбасары; |
| Кәримов Хәлим Газиз улы | – комиссия әгъзасы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Иҗтимагый советы рәисе (килешү буенча); |
| Вафина Зөлфия Ягәфәр кызы | - комиссия секретаре, Мамадыш муниципаль районы Советының оештыру эшләре бүлеге башлыгы урынбасары; |

6. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү турында хәбәрне «Нократ» («Вятка») газетасында урнаштырырга.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.//pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы рәсми сайтында (mamadysh.tatarstan.ru) урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башлыгы урынбасары Р.Р. Сәмигуллинга йөкләргә.

Мамадыш муниципаль
районы Башлыгы В.И.Никитин